КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 14 июль г.Казань № 588

Татарстан Республикасында Татарстан Республикасының дәүләт белем бирү оешмаларында һәм муниципаль белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы укучылар саныннан 100 процент колачлауны тәэмин итүче әлеге белем бирү оешмаларында шундый укучыларның түләүсез кайнар ризык белән туклануын оештыру чаралары исемлеген раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасында Татарстан Республикасының дәүләт белем бирү оешмаларында һәм муниципаль белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы укучылар саныннан 100 процент колачлауны тәэмин итүче әлеге белем бирү оешмаларында шундый укучыларның түләүсез кайнар ризык белән туклануын оештыру чаралары исемлеген (алга таба – Чаралар исемлеге) расларга.

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетына, Татарстан Республикасының дәүләт белем бирү оешмалары җитәкчеләренә түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга, шулай ук Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына, муниципаль белем бирү оешмалары җитәкчеләренә – гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә:

Чаралар исемлеге үтәлешен тәэмин итүне;

аларны үтәү барышы турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына Чаралар исемлегендә күрсәтелгән вакытларда кертүне.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына бу карарның 2 нче пункты нигезендә алынган мәгълүматны гомумиләштерергә һәм хисап чорыннан соң килә торган айның 30ына кадәр аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

4. Исемлектә күрсәтелгән чараларны финанслау тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнарына каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин